КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 8 июль г.Казань № 537

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 июль, 455 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 701 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 13 ноябрь, 866 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 102 нче; 2019 ел, 25 февраль, 125 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 775 нче; 2020 ел, 2 апрель, 250 нче; 2020 ел, 6 июль, 555 нче; 2021 ел, 21 апрель, 268 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2022 ел, 12 декабрь, 1316 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1493 нче; 2023 ел, 1 март, 195 нче; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче; 2023 ел, 13 июль, 823 нче; 2023 ел, 27 июль, 899 нчы; 2023 ел, 23 август, 1003 нче; 2023 ел, 31 август, 1054 нче; 2023 ел, 4 сентябрь, 1067 нче; 2023 ел, 10 октябрь, 1293 нче; 2023 ел,

11 декабрь, 1599 нчы; 2023 ел, 19 декабрь, 1645 нче; 2024 ел, 13 февраль, 76 нчы; 2024 ел, 25 май, 365 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге Тәртипкә 6 нче кушымтада:

«Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәкләренең наркомания белән авыручыларны социаль тернәкләндерү бүлекләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү исемнәре, аларның тасвирламасы һәм күләме» таблицасының 5.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «5.2. | Юридик хезмәтләрдән файдалануда ярдәм күрсәтү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>законнар белән билгеләнгән ташламаларны алу, юридик ярдәмнән файдалану, шул исәптән «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 324-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә түләүсез юридик ярдәмнән файдалану мәсьәләләре (юридик бюро адреслары, телефоннары, эш режимнарын бирү) буенча консультация бирү; | чаралар комплексы | социаль хезмәт күрсәтү чорында 1 тапкыр |
| | | социаль-хокукый (граждан, торак, хезмәт, пенсия, җинаять законнары һ.б.) мәсьәләләр буенча әлеге мәсьәләләрне хәл итә торган органнар, оешмалар вәкилләренең социаль хезмәтмәтләр күрсәтелүчеләргә консультацияләр бирүен оештыру; | чаралар комплексы | социаль хезмәт күрсәтү чорында 1 тапкыр |
| | | социаль ярдәм чаралары, социаль түләүләр, пенсияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында, | чаралар комплексы | социаль хезмәт күрсәтү чорында |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | шул исәптән әлеге мәсьәләләрне хәл итә торган органнар, оешмалар вәкилләрен чакырып, мәгълүмат бирү; социаль ярдәм чаралары, социаль түләүләр, пенсияләр билгеләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтү; гаризаны һәм документларны вәкаләтле органга тапшыруда ярдәм күрсәтү; вәкаләтле органда социаль ярдәм чаралары, социаль түләүләр, пенсияләр билгеләү өчен кирәкле документларны карау барышын контрольдә тоту | | 1 тапкыр»; |

«Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең наркомания белән авыручыларны социаль тернәкләндерү бүлекләрендә социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләргә социаль булышлык итү хезмәтләре исемнәре һәм стандартлары» таблицасы үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин